**Татар телендә гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сораулары**
**(муниципаль тур, 2022-2023 уку елы) 7 нче сыйныф**

**Максималь балл – 55 балл**

**Җаваплар**

**I. Теоретик бирем (15 балл).**

1.Халык авыз иҗаты әсәрләре һәм язма әдәбият әсәрләре арасындагы аермаларны санап чык һәм һәр ике төр әсәрләргә дә өчәр мисал яз. (10 балл)

***Халык авыз иҗаты әсәрләре телдән иҗат ителеп, телдән-телгә күчеп саклана. Аның авторы, язылу вакыты билгеле булмый. Алар язмача теркәлми калырга да мөмкин. Телдән-телгә күчеп саклanулары аларның төрле вариантлары барлыкка килүенә сәбәп була. Һәр сөйләүче аны үзенчә баета, үз максатларына яраклаштырып куя. Шуның өчен ул күмәк иҗат характерында була. Халык авыз иҗаты әсәрләрендә жанр чикләре төгәл аерылып тормаска да мөмкин, ул синкретик характерда. Мәсәлән, бер үк вакытта бию, җыр, драматик хәрәкәтләр дә кушылып китә. Халык иҗаты әсәрләрендә әзер образлар, билгеле бер калыпка салу, шаблон куллану сизелә. Халык иҗаты әсәрләре тыңлаучыны, аның зәвыгын күздә тота, тыңлаучыга мөрәҗәгать алгы планга чыга. Халыкның көнкүреше белән турыдан-туры бәйлелектә була.***

***Язма әдәбият билгеле бер авторның, язма формада укучысына җиткергән әсәре. Язмача теркәлгәнгә аңа вариантлылык хас түгел (әгәр автор үзе үзгәртеп эшләмәсә). Язылу вакыты да билгеле (аерым чыгарылма булуы мөмкин, автор әсәренең төгәл язылу датасы ачык булмаган очрак була ала). Автор әсәрләрендә жанр чикләре төгәл, әсәр төзелеше һәм образлар системасы, язучының стиле ачык билгеләнгән була.***

2 Әдәби төшенчәгә бирелгән аңлатма дөрес булырлык итеп, төшеп калган сүзләрне куй. (5 балл)

Аерым халыкның тарихына, мифологик ышануларына нигезләнгән героик эчтәлекле, романтик рухлы, эпик әсәр **дастан** дип атала. Геройлары мәхәббәт һәм бәхет өчен көрәшүче гашыйк затлар булса, мондый әсәрләр **мәхәббәт дастаны** була.

**II. Өзекне укы һәм тәкъдим ителгән сорауларга җавап бир. (15 балл)**

Кич гаҗәеп гүзәл иде, каралҗым күк йөзен аксыл җәүһәр кисәкләре төсле балкып торган хисапсыз шаян йолдызлар бизи, җирдә диңгез буйлап куе караңгылыкны ачып җибәргән саргылт-кызыл факеллар яна. Ерак-ераклардан чит промыслоларда яндырылган шундый ук факелларның төмсә (тонык) һәм

юаш утлары караңгы диңгез буйлап су өстеннән күңелгә ягымлы йомшак нур сызыклары җибәреп торалар. Алар диңгез өстендә гүя елмаялар, гүя көләләр. Әллә нинди төпсез тирәнлек һәм серләр эчендә уйнап, җанга аңлашылмаган бер дәрт, җылылык һәм рәхәтлек бирәләр. Кайсылары ераклардан чагылып, гүя елый-елый әкренләп сүнәргә торалар, кемнедер бәхилләшергә чакыралар... Диңгез ягыннан искән йомшак кына җил, чак хис итәрлек таза су һәм тоз исләре аңкытып, битләрне сыйпый, миләрне кытыкландырып, күңелләрне рәхәтләндерә иде.

1.Әсәрнең исемен, жанрын һәм авторын язып куй. (3 балл)

***«Акчарлаклар», повесть, Шәриф Камал.***

2. Әсәрнең темасын, проблемасын һәм автор идеясен ачыклап яз. (6 балл)

***Әсәр гади хезмәт кешесенең бәхете, сезонлы хезмәткә ялланган эшчеләр тормышы турында. Сюжет сызыгының ике тармагы: балык тоту, акча эшләргә омтылу һәм Гариф белән Газизәнең әкрен генә үстерелә барган хисләре тарихы. Автор ару-талусыз эшләргә сәләтле, ярдәмчел, гади, чиста күңелле хезмәт кешесенең бәхетсезлегенең сәбәпләрен эзли. Әсәрдә кешене бәхетле итәргә, теләк максатларына якынайтырга тиешле хезмәт ни өчен бәхет китерми дигән проблема куела. Ш. Камал «кеше хезмәте белән бәхетле» дигән фикерне ассызыклый. Хезмәткә күңел бирү, аңа яшәү чыганагы итеп карау, һәр эшкә күтәренке күңел белән кумәкләшеп керешү, Газизәнең дә башкалар янына эшкә омтылып торуы, эш булмаганда эч пошу һ.б. Ш.Камалның кеше тормышында хезмәтне алга куюын күрсәтә. Әмма нәтиҗәсе булмаган эш, башкалар кесәсен баету өчен генә хезмәт итү кешене бәхетле итә алмый, киресенчә, өмете киселеп, канатсыз кош хәленә китерә. Акчарлаклар белән эшчеләрне янәшә куеп, автор әсәрнең идеясен ача. Кешене максатына илткән, өметләрен тормышка ашырырга ярдәм иткән хезмәт кенә кешене бәхетле итә. Гаделсезлеккә, эксплуатациягә корылган капиталистик җәмгыятьтә бу мөмкин түгел. Әмма хезмәт кешесенең төшенкелеккә бирелмәвен сурәтләве аша, автор аның бәхеткә ирешәчәгенә ышаныч белдерә.***

3. Әсәрдә кайсы образ психологик яктан тирәнтен ачылган? Аның эчке күңел кичерешләре, рухи дөньясы кайсы вакыйгаларда ачыла? Шул хакта яз.(6 балл)

***«Акчарлаклар» повестенда Гариф образы психологик яктан тирәнтен ачылган образ. Автор аның белән, иң элек, көчле, таза егет буларак таныштыра. Гариф сүзнең кирәген генә сөйли, иптәшләре арасында дәрәҗәле, кешеләр белән тиз аралаша, уртак тел таба белә торган егет. Ул һәрнәрсәне күзәтә, күңеле аша үткәрә. Бу аның хезмәткә килеп урнашуының беренче көннәрендә дә, Шәрәфи агай гаиләсендә Газизәне тәүге тапкыр күргәндә һәм аның белән соңгы саубуллашуында да чагыла. Аның рухи кичерешләре «Егет елый иде» дигән бүлектә тирәнтен ачыла. Гарифның күңел дөньясы, үзе генә белгән хатирәләре,***

***истәлекләре, киләчәккә өметләре бар. Язучы Гарифны хисләргә бай, тормышны җаны аша үткәрүче нечкә күңелле шәхес буларак ача. Бу бүлектә без аның күңелендә кинәт ике хис бәрелешүен күрәбез. Шыксыз бушлык, үткәннәрнең авыр хатирәсе. Тәмле ризык, ягымлы сүз, гаилә җылысы күрми төрле җирләрдә үткәрелгән вакытлар – болар бөтенесе күңелне катырган, хисләрне эчкә яшерергә өйрәткән. Әмма Шәрифи карт гаиләсендәге җылы мөнәсәбәт, кайгыртучанлык, Газизәнең ягымлы мөгамәләсе, ярдәмчеллеге аның хисләре ташуга сәбәп була. Ул гомере буе көтеп яшәгән күңел җылысын таба. Тормышын күңеленнән кичерә, күз яшьләренә ирек бирә. Бу бүлектә Гарифның эчке дөньясы, психологик халәте тулысы белән ачыла.***

## III. Шигъри әсәр белән эш. (14 балл)

Әй авыл, син мең шәһәрдән
Мең кабат ямьле вә хуш:
Бер кеше юк бер урамда...
Нинди тын һәм нинди буш.

Нинди иркен, нинди рәхәт,
Нинди бар җир гөл генә;
Синдә төн дә юк, төнең дә
Бер болытлы көн генә.

Ул кара бер күгеңә – бу
Фирүзә бит, бик зуры,
Күр аеңны, кайда бар бу?
Бер гаҗәеп бит нуры!

Нинди нурлар сачрәтеп ул
Уйный, нәкъ нурда йөзә,
Нәкъ көлә, нәкъ елмая, нәкъ
Юри бәгъреңне өзә.

Нинди тамчы-тамчы нурлар
Сачраган күк йөзенә,
Чеп-чуар чын бриллиант
Сипкәнмени, күр үзенә.

Һәм гаҗиб бер яктылыкта
Җир көмеш төсле тора:
Анда – урман һәм дә таулар,
Монда кырлар яктыра.

Синдә бар да чын матур һәм
Чын матур синдә генә,
Тагы да артыр бер матурлык,
Китдисәм мин дә менә.
(С. Рәмиев «Авыл»)

1.Рифмалашкан сүзләрне табып, парлап яз. (3 балл)
***Хуш – буш, гөл генә – көн генә һ.б.***
2. Шагыйрь авыл табигатен тасвирлау өчен нинди образларга мөрәҗәгать иткән? Чагыштыру һәм метафораларны табып күрсәт.(6 балл)

***Лирик герой авыл табигатенең матурлыгын ачу өчен, иң элек, аны шәһәргә каршы куя (мең шәһәрдән, мең кабат ямьле вә хуш). Ул авылның төнге табигатен тасвирый. Төнге авылның матурлыгын, тынлыгын сурәтләү өчен ул гаҗәеп матур чагыштырулар таба. Аның төне дә бер болытлы көн кебек якты. Укучы алдына авыл төненең искиткеч матур картинасын ясап куя. Күк йөзе – фирүзә (асылташ), йолдызлар – бриллиант, җир – көмеш сыман.***

3. Лирик герой үзеннән канәгатьме? Бу фикер шигырьнең кайсы юлларыннан аңлашыла. Шул шигырь юлларына нигезләнеп, аның күңел халәтен әйтеп бир. (5 балл)
***Лирик геройның үзеннән канәгатьсезлеге сизелә. Ул үзен бу матурлыкның ямен җибәрүче буларак күрә: Тагы да артыр бер матурлык,***
***Китдисәм мин дә менә.***
***Бу юлларда лирик геройның үз-үзеннән ризасызлыгы, күңел төшенкелеге аңлашыла.***

**IV. Телнең тәмен беләсеңме?(3 балл)**

1.Бирелгән сүзләрнең мәгънәсен аңлатып яз.(1,5 балл)
а) илтифат – ***игътибар***
ә) шөһрәт – ***дан, дәрәҗә***
б)вәхши – ***явыз, ерткыч***

2.Бер өлеше бирелгән мәкальләрнең, дөрес итеп, икенче яртысын табып яз. (1.5 балл)
а)Балның үзе тәмле, *авызның сүзе тәмле*.
ә)Аяк белән абынудан, *тел белән абыну яман.*
б) Акыллы бер тапкыр алданыр, *акылсыз мең тапкыр алданыр.*

**V. Иҗади эш. (8 балл)**

Татарстанга килгән кунак синнән татар театры турында сораса, син аңа нәрсәләр сөйли аласың? Ирекле формада шул хакта яз.

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сораулары**
**(муниципаль тур, 2022-2023 уку елы) 8 нче сыйныф**

**Максималь балл – 53 балл**

**I. Теоретик бирем (15 балл).**

1.Мәгърифәтчелек реализмына хас үзенчәлекләрне санап чык. (10 балл)

***Кешене аң-белемгә өндәүче, югары идеалларга хезмәт итәргә чакыручы, җәмгыятьне үзгәртүне гаиләдән башларга кирәклекне раслый торган иҗат агымы.***
***төп сыйфатлары:***
***гыйлемлелек, мәрхәмәтлелек, тәрбияле булуны мактау, геройның әхлакый камиллеген белем алу белән бәйләнештә карау;***
***әсәрләргә шартлылыкның хас булуы;***
***геройларның уңай һәм тискәрегә кискен аерылуы, гамәлләренең, язмышларының иҗтимагый шартларга бәйле мотивлаштырылган булуы;***
***әхлакый, мәгърифәтчелек идеалларының югары күтәрелүе.***

2 Әдәби төшенчәгә бирелгән аңлатма дөрес булырлык итеп, төшеп калган сүзләрне куй. (5 балл)

***Стиль*** – әдәби әсәрнең укучы тарафыннан эчтәлек һәм форма берлегендә бөтенлекле кабул ителүен тәэмин итә торган эстетик категория. Бер язучының төрле әсәрләрендә күзәтелә торган уртак сыйфатлары ***язучы стиле*** була. Берничә язучы иҗатындагы уртаклык ***чор стилен*** барлыкка китерә.

**II. Өзекне укы һәм тәкъдим ителгән сорауларга җавап бир. (14 балл)**

*Биек таш коймa белән чолганган киң һәм озын бу ишегалды, таш белән түшәлгәнлегенә карамыйча, ямь-яшел үләнлеккә әйләнгән, әүвәл заманнарда гөрләп, шаулап торган бу ишегалды хәзер әллә нинди серле тынлык, җанны авырайта торган тынлыкка батып калган иде. Ишекләре кәкрәйгән сарайлар, урыны-урыны белән түбә калайлары купкан амбарлар, ташланган кое, түрдә күренеп торган, искергән һәм бераз артка таба ауган рәшәткәле бакча коймасы бу хәятсыз ишегалдына әллә нинди, җанга авыр булып торган шыксызлык һәм ташландыклык төсе биреп тора иде.*

1.Әсәрнең исемен, жанрын һәм авторын язып куй. (3 балл)

***«Бер хәрәбәдә», хикәя, Ф. Әмирхан***

2.Әсәрдә хикәяләүче тасвирлаган вакыйгалар үткән һәм хәзер рәвешендә икегә бүленә? Үткән һәм хәзерге тормышның аермасы нәрсәдә булуын тасвирлап бир. Әлеге аерманы аңларга ярдәм иткән образларны санап күрсәт. (6 балл)

***Хикәяләүче күңелендә матур хатирәләр сакланган Сөләймән агай йортына килә. Кайчандыр тормыш кайнап торган, шат авазлар, белән тулы кунакчыл йорт, яшьлек матурлыгы белән янып торган Фәрхия һәм Әсма, бөтен җирдән җитешлек, зәвыклылык сизелеп торган корылмалар, һәр почмагы оҗмахтай булган тәрбия итеп торылган бакча һ.б. – барысы да үткәннең хәтирәләре. Хәзер боларның берсе дә калмаган, йорт та, кешеләр дә танымаслык булып үзгәргән. Ул үткәннәрнең хәрабәсе белән – яшьлек, матурлык, мәхәббәт, байлык, тәртиптән калган җимерекләре белән очраша. Үткәндә булган һәм хәзергене ул янәшә куеп сөйли. Бу каршылыкны укучыга җиткерү өчен капма-каршы куелган образлар системасын булдыра. Гөл – тигәнәк, әрекмән, кычыткан; фәрештә – өрәк, былбыл – карга, матурлык – хәрабә, яшьлек-картлык, музыка–ямьсез авазлар(бакчадагы куркыныч тавышлар, капка, ишек шыгырдавы, шыксыз тынлык) һ.б.***

3.Әсәрдә хикәяләүче үзе өчен нинди хакыйкатьне ача? (5 балл)

***Әсәрдә хикәяләүче тормыш мәгънәсенә төшенә, яшәүнең чиклелеген аңлый. Бу дөньяда бар нәрсәнең вакытлы, үзгәрүчән булуын бар нәрсәнең үтүен, югалуын таный. Бер нәрсә дә мәңгелек түгел дигән хакыйкатькә төшенә. Шул аның күңелендә сызлану тудыра.***

## III. Шигъри әсәр белән эш. (13 балл)

Менә кич. Зур авыл өстендә чыкты нурлы ай калкып,
Көмешләнгән бөтен өйләр, вә сәхралар тора балкып.

Авыл тын. Иртәдән кичкә кадәр хезмәт итеп арган
Халык йоклый – каты, тәмле вә рәхәт йокыга талган.

Урамда өрми этләр дә, авыл үлгән, тавыш-тын юк;
Авыл кырыенда бер өйдә фәкать сүнми тора бер ут.

Әнә шул өй эчендә ястүеннән соңра бер карчык
Намазлыкка утырган, бар җиһаннан күңелен арчып;

Күтәргән кул догага, яд итә (*искә ала*) ул шунда үз угълын:
Ходаем, ди, бәхетле булса иде сөйгән, газиз угълым!

Тамадыр мескинәмнең тамчы-тамчы күзләреннән яшь;
Карагыз: шул догамы инде Тәңре каршына бармас?
(Г. Тукай. Ана догасы)

1.Рифмалашкан сүзләрне табып, парлап яз. (3 балл)
***Калкып – балкып, арыган – талган, һ.б.***
2. Лирик геройның кичерешләрен аңлатып яз. (5 балл)

***Лирик герой төнге авыл күренешеннән хозурлана. Кичке тынлыкка чумган авылның бар матурлыгын күңеле аша үткәреп тасвирлап бирә. Аның күңелендәге тынычлык, соклану, шул тынлыкны үз итү яратучагыла. Шигырьнең икенче өлешендә ул тын авылның икенче бер бизәгенә игътибар итә. Бар кеше йоклаган, авыл илаһи тынлыкка чумган бер мәлдә намазлык өстендә үз улына ихластан бәхет теләүче карчык. Лирик герой аның белән теләктәшлек итә. Үзе дә бу теләкнең кабул булуына ихластан ышана. Шигырьдә лирик геройның күңел матурлыгы ихласлыгы да чагыла.***

3. Шигырьдә ана догасының ихласлыгын автор ничек гәүдәләндерә? Шуны ачарга ярдәм иткән гыйбарәләрне язып куй. (5 балл)

***Шагыйрь ана догасының ихласлыгын ачу өчен кешене Аллага якынайтучы гамәлдә, намаз уку һәм дога кылу хәлендә сурәтли. Дога вакытнда кеше үзен Алла белән турыда-туры бәйләнештә сизә, аңа ихлас теләкләрен белдерә. Бу шигырьдәге "бар җиһаннан күңелен арчып, ястүеннән соңра, намазлыкка утырган, күтәргән кул догага, мескинәмнең тамчы-тамчы күзләреннән яшь тама" гыйбәрәләрендә чагылыш таба.***

**Телнең тәмен беләсеңме? (3 балл)**

1.Бирелгән сүзләрнең мәгънәсен аңлатып яз. (1,5 балл)
а) нәсыйхәт – үгет, яхшы киңәш.
ә) ләгънәт – каргыш, рәнҗеш, үпкәне белдерүче сүз
б) хәрабә – җимереклек

2.Бер өлеше бирелгән мәкальләрнең, дөрес итеп, икенче яртысын табып яз.(1,5 балл)
а)Туган телен оныткан, *туган җирен югалткан*.
ә) Кирәклесе күп булыр, *туган телең бер булыр*.
б)Туган илне, туган телне, *беркем дә сайлап ала алмас*.

**V. Иҗади бирем. (8 балл)**

Татарстанга килгән кунакны син татар халкының нинди бәйрәмнәре белән таныштыра аласың? Берәр бәйрәмне мавыктыргыч итеп сөйләп бир.

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сораулары (муниципаль тур, 2022-2023 уку елы) 9 нчы сыйныф**

**Максималь балл – 49 балл**

**I. Теоретик бирем ( 10 балл).**

1.Борынгы һәм Урта гасырлар әдәбияты нинди чорларны үз эченә ала. (7 балл)

***Борынгы әдәбият***

*Гомумтөрки әдәбият (V—XII йөзләр)*

***Урта гасырлар әдәбияты***

*Болгар чоры әдәбияты (IX—XIII гасырның I чиреге)*
*Алтын Урда чоры әдәбияты (XIII гасыр уртасы — XV гасыр уртасы)*
*Казан ханлыгы чоры әдәбияты (XV гасыр уртасы — XVI гасыр уртасы)*
*Торгынлык чоры әдәбияты (XVI гасыр уртасы — XIX гасыр уртасы)*

2 Әдәби төшенчәгә бирелгән аңлатма дөрес булырлык итеп, төшеп калган сүзне язып куй. (3 балл)

**Традиция** – үткән чорларның актуаль һәм кыйммәтле дип кабул ителгән, үзләштерелгән яисә иҗат ориентиры итеп алынган тәҗрибә.

**II. Өзекне укы һәм тәкъдим ителгән сорауларга җавап бир. (15 балл)**

*Майның бер якшәмбесе, көндезге сәгать өчләр иде. Бер сәгать кенә моннан әүвәл явып киткән җиңел яңгыр шәһәр урамнарының тузанын баскан һәм, һавадагы кызулыкны җиңелчә язгы җылылык белән алмаштырып, көнне ямьлелекнең чигенә ирештергән иде. Әле һаман һавадан җуялып бетмәгән яз җиле кояш батышы ягыннан аерым бер акрынлык һәм тынычлык белән исә дә дөньяга яңару һәм яшәрү исләре чәчә һәм бөтен җанлы һәм җансыз нәрсәләрне үзләренә бер төрле тереклектә коендыра иде.*

1.Әсәрнең исемен, жанрын һәм авторын язып куй. (3 балл)

***“Хәят”, романтик повесть, Фатих Әмирхан.***

2. Әсәрнең темасын, проблемасын, идеясен яз. (6 балл)

***Әсәр татар хатын-кызлары язмышы темасына язылган. Әсәрдә татар хатын-кызларының язмышы, рус һәм татар хатын-кызларының җәмгыятьтәге урыны, хокуклары; милли традицияләрне, гореф-гадәтләрне саклау проблемасы куела. Автор әсәрендә хатын-кыз үз бәхете өчен көрәшергә хаклы, әмма ул гореф-гадәтләрне, милли яшәеш кануннарын җимермәскә тиеш дип раслый.***

3. Әсәрдә кайсы образ психологик яктан тирәнтен ачылган? Аның эчке күңел кичерешләре, рухи дөньясы кайсы вакыйгаларда ачыла? Шул хакта яз. (6 балл)

***Әсәрдә Хәят образы тирән психологик кичерешләре аша ачыла. Татар гаиләләрендәге кызларның һәммәсенә дә мөмкин булмаган иркенлектә, рус мохитендә үскән Хәят җиту кыз булып өлгерә. Үзенең күз явын алырлык матурлыгы белән ул күпләрнең күңелен җәлеп итә. Иң элек балалык дусты булган Михаил аңа мәхәббәтен белдерә. Хәят та Михаилны ярата. Әмма кыз әлеге саф хисләрнең кайсыдыр җирендә китеклек сизә. Дачадагы кичәдән соңгы кичерешләре Хәятнең күңелен бөтен нечкәлекләре белән ачып бирә. Тәүге сөю хисе белән канатланган фәрештәдәй саф күңел, "Михаил кяфер бит", дигән нәтиҗә белән сүнеп кала. Шул көннән аның күңелендә пошыну, тынгысызлык башлана. Әлегә кадәр бер-берсе белән каршылыкка кермәгән ике төрле тормыштан ул Мясниковларча яшәүнең аның өчен булмаганлыгын аңлый. Икенче яктан ул ирекле рәвештә, үзе теләгән татар егетләре белән танышуның да рөхсәт ителмәгәнлеген белә. Гали Арслановның игътибарына да җавап бирә алмый. Әнисе Салихның фотосын биргәннән соңгы уйланулары, хыялы да Хәятның эчке дөньясын сурәтләүгә юнәлтелгән. Аны ирксезләүче дә юк, әмма ул гасырлар дәвамында калыплашкан гадәтләрне дә җимерергә тиеш түгеллеген аңлый. "Илаһи, мәхәббәт бир!" – дигән ихлас теләге белән язмышына буйсына. Автор Хәятның гаиләсен, тәрбиясен, мохитен һәм шулар эчендәге рухи халәтен бөтен нечкәлеге белән ачып бирә.***

**III. Шигъри әсәр белән эш. (13 балл)**

Бездә хәзер ямьле яздыр, иркәм,
Көн кояшлы, төннәр айлыдыр,
Идел буендагы бакчаларда
Сыерчыклар ярсып сайрыйдыр.

Кошлар моңы уятадыр сине,
Челтәр пәрдәләрне күтәреп,
Язгы таңны күзлисеңдер ялгыз
Чәчәк аткан гөлләр үтәли.

Ә биредә, без фашистлар белән
Бугазлашкан урман, кырларда,
Күңел өчен бер генә кош та юк
Язны хәтерләтеп җырларга.

Дулкынланып, шаулап торган урман
Сынып беткән, изрәп тапталган,

Чәчәк үсә торган киң болыннар
Кеше каны белән тапланган.

Фашист тырнагына капкан кеше
Сыкранмыйча монда тын алмый,
Янган авылларның төтеннәре
Язгы таңның нурын томалый.

Фашист илгә үлем генә китерә.
Фашизмның таңы, язы юк.
Яшен уты белән күккә язып әйтәм:
Язы юкның яшәү хакы юк! (Ф. Кәрим. Бездә яздыр)

1.Рифмалашкан сүзләрне табып, парлап яз. (3 балл)
***Айлыдыр – сайрыйдыр, күтәреп – үтәли, һ.б.***
2. Лирик геройның кичерешләрен аңлатып яз. (5 балл)

***Лирик герой фашизмга каршы көрәшүче солдат. Ул тыныч туган җире белән фашист тырнагына эләккән, кеше канына буялган кырларны чагыштыра, дошманның явызлыгын, яшәешнең бөтен матурлыгын җимерүен сөйли. Анда яз матурлыгы да, гөлләр дә, сайрар кошлар да юк. Туган җирдә калганнарның да күңелен ялгызлык ачысы тырный. Лирик герой күңелендә фашизмга нәфрәт ята. Ул аның җимергеч көч булуын, тормышны, яшәешне юк итүен дәлилли. Кешелек өчен афәт булган мондый вәхшинең яшәргә хакы юк икәнлеген раслый.***

3. Яз образына шагыйрь нинди мәгънә салганлыгын аңлатып бир. (5 балл)

***Әсәрдә яз образы яшәеш, тереклек, яңару белән тиңләштерелә. Фашист аяк баскан җирдә яшәү уты сүнә, тереклек үлә (...***бер генә кош та юк,//Язны хәтерләтеп җырларга. *яки* Янган авылларның төтеннәре // Язгы таңның нурын томалый.)

***. “Фашизмның таңы, язы юк”,– ди шагыйрь. Җирдә яшәү утын сүндергән көчнең үзенең дә яшәргә хакы юк дип раслый.***

**IV.Телнең тәмен беләсеңме? (3 балл)**

1.Бирелгән сүзләрнең мәгънәсен аңлатып яз. (1,5 балл
***а) афәт – фаҗига, бәлә-каза.***
***ә) тәвәккәл – кыю***
***б) нахак – нигезсез, расланмаган, дәлилләнмәгән***.

2.Бер өлеше бирелгән мәкальләрнең, дөрес итеп, икенче яртысын табып яз. (1,5 балл)
а) Яхшыны ишетргә теләсәң, *яман сүз сөйләмә*.
ә) Ямансыз яхшы булмас, *яхшысыз яман булмас*.
б) Яхшыдан яман чыкса да, *яманнан яхшы булмас*.

**V.Иҗади эш. (8 балл)**

Татарстанга килгән кунакны син татар халкының нинди милли киемнәре һәм аларның бизәлеш үзенчәлекләре белән ничек таныштырырсың? Шул хакта яз.

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сораулары**
**(муниципаль тур, 2022-2023 уку елы) 10 нчы сыйныф**

**Максималь балл – 60 балл**

**Җаваплар**

**I. Теоретик бирем (13 балл).**

1.Совет чоры әдәбияты нинди чорларга бүлеп өйрәнелә? (8 балл)

***Совет чоры әдәбияты 1917 – 1950 еллар ахырына кадәрге вакытны үз эченә ала һәм түбәндәге бүленештә өйрәнелә:***
***1)Инкыйлаб һәм гражданнар сугышы чоры – 1917 – 1921еллар***
***2)Егерменче еллар әдәбияты – 1921 – 1932 еллар***
***3) Утызынчы еллар әдәбияты – 1932 – 1941 еллар***
***4)Бөек Ватан сугышы еллары әдәбияты – 1941– 1945 еллар***
***5)Сугыштан соңгы чор әдәбияты – 1945 – 1950 еллар ахыры.***

2 Әдәби төшенчәгә бирелгән аңлатма дөрес булырлык итеп, төшеп калган сүзне куй. (5 балл)

Вакыйгаларны, кешеләрне, аларның тормыш-яшәешен, үзара мөнәсәбәтләрен чынбарлыктагыча сурәтләүгә нигезләнгән, кеше характерындагы психологик үзенчәлекләрне иҗтимагый шартлар белән тыгыз бәйләнештә тасвирлаган иҗат юнәлеше ***реалистик*** иҗат юнәлеше була.

**II. Кол Гали иҗатына карагансорауларга җавап бир. (16 балл)**

1.Кол Гали яшәгән вакытны (гасырын) күрсәт. (2 балл)

***XIII гасыр***

2. Кол Гали иҗат иткән әсәрнең исемен, жанрын язып куй. (2 балл)

***“Кыйссаи Йосыф”, лиро-эпик поэма.***

3. Әсәрнең темасын, проблемасын һәм автор идеясен ачыклап яз. (6 балл)

***Әсәрнең төп темасы – шәфкатьлелек, ислам кануннарына нигезләнгән тормыш.Әсәрдәге барлык вакыйгалар да шәфкатьлелек яки шәфкатьсезлек кылучыга җәза килүгә бәйле ачыла.Әсәрнең проблемасы явызлыктан ничек котылырга, кешеләрне ничек тату яшәтергә, ничек гадел хөкемдарлы имин дәүләт булдырырга дигән сорауларга җавап эзләүгә кайтып кала. Автор проблеманы чишү юлларын шәфкатьлелек, явызлыка яхшылык белән җавап бирү, тугрылык, сабырлык, ислам кануннарын саклап яшәүдә таба. Автор идеясе явызлыкны үстермәскә, аны яхшылык белән юк итәргә чакыра. Кылган һәр гамәл өчен кеше үзе җаваплы, нәтиҗәсен дә үзе күтәрә дип аңлата. Камиллеккә омтылырга кешелек дәрәҗәсен югары тотарга чакыра.***

4.Йосыф образына тулырак бәя бир. Аңа хас сыйфатларны санап чык. (6 балл)

***Кол Гали Йосыф үрнәгендә камил шәхес образын гәүдәләндерергә омтыла. Шуңа ул аның пәйгамбәр нәселеннән икәнлеген белдерә. Ул шәфкатьле, гадел, сабыр, тирән фикерләүче, алдан күрүче, тугрылыклы, күркәм холыклы. Алланың барлыгына, Берлегенә ышану, аңа таяну, ярдәмне дә аннан гына сорау аның төп сыйфатларыннан. Йосыф тышкы матурлык белән күңеленең матурлыгын берләштергән, рухи камиллеге аның йөзенә нур булып кунган. Йосыфка хас сыйфатлар түбәндәге юлларда төгәлләштерелгән (Укучы шуңа да нигезләнә ала):***

«Беренчедән – буе зифа, сылу үзе,
Икенчедән – күрекле һәм якты йөзе,
Өченчедән – теле бик саф, туры сүзле,
Җитмеш ике телне тәмам белә имди!

Дүртенчедән – кешелекле һәм шәфкатьле,
Бишенчедән – Алып батырдай гайрәтле,
Алтынчыдан – бик күпләрдән ул куәтле, —
Көче аның кырык ирдән артык имди.

Җиденчедән – дине бөтен, диянәтле,
Сигезенче – хыянәтсез,әманәтле,
Тугызынчы – холкы гүзәл, теле татлы,
Унынчыдан – пәйгамбәрләр нәсле имди».

Бер кеше дә аны сатып алалмады,
Бәһа биреп, аңа якын килалмады,
Мисыр малы аңа бәһа булалмады, –
Җиһан малы аның өчен җитми имди!

**III. Шигъри әсәр белән эш. (20 балл)**

Яңгырларда-явымнарда,
Давылларда, җилләрдә
Киек казлар кыйгылдаша
Мин белмәгән телләрдә.

Киек казлар кыйгылдаша,
Җырлашалар миккәнни?
Туган илләр кала бит дип
Елашалар микәнни?

Безнең дә бит шулар сыман
Киткән еллар бар иде;
Кыйгак-кыйгак, илем ерак,
Дигән чорлар бар иде.

Киек казлар кыйңылдаша,
Сау бул, якташ, диләрдер;

Әллә кайтыр, әллә кайтмас
Безнең башлар, диләрдер.

Казлар кебек очасылар,
Китәселәр юк инде;
Кыйгак –кыйгак, илем ерак,
Дияселәр юк инде.

Кыйгылдашып болытларда,
Мин белмәгән телләрдә
Киек казлар китеп бара
Мин күрмәгән илләргә. (Х. Туфан. Киек казлар)

1.Рифмалашкан сүзләрне табып, парлап яз. (3 балл)

***Җилләрдә – телләрдә, җырлашалар – елашалар, киткән еллар – дигән чорлар һ.б.***

2.Шигырьдәге тел-сурәтләү чараларын табып күрсәт. (6 балл)

***Киек казлар елаша, җырлаша, сау бул якташ диләр – сынландыру, казлар кебек – чагыштыру.***

3. Лирик геройның кичерешләрен аңлатып яз. (5 балл)

***Туган җирдән китеп барган киек казларның тавышы лирик герой күңелендә моңсулык уята, туган җирдән аерылу сагышының ачысы булып күңеленә үтеп керә. Казлар тавышы җыр да, елау да булып яңгырый. Күңелендәге хәтирәләрне кузгата. Казлар кебек туган җирдән, газиз кешеләреннән аерылып китән вакытларны искә төшерә. Инде андый авырлыкларның артта калуы аның күңелендә юаныч уята. Давыл, яңгыр, җыр образлары, тәэсирлелекне арттыра. Туган илдән аерылу сагышын, алдагы билгесезлек төшенчәсен тирәнәйтә. Укучыга лирик герой кичерешләрен тирәнрәк аңарга ярдәм итә.***

4. Лирик герой кичерешләрен автор язмышы белән ничек бәйләп карарга мөмкин? Шул хакта яз. (6 балл)

***Хәсән Туфанның нахак бәла белән хөкем ителүен, халык дошманы буларак гомерлек сөргенгә озатылуы, озак еллар туганнары, хатыны һәм балаларыннан еракта, хокуксыз зат буларак гомер кичерүе, акланганнан соң да бер еллап каратинда булып бик зарыгып туган җиренә кайтып төшүен, ул кайтканда инде улы белән хатынының вафат булуларын искә алганда лирик геройның күңел кичерешләре авторныкы белән тәңгәл булуын аңларга була.***

**Телнең тәмен беләсеңме? (3 балл)**

1.Бирелгән сүзләрнең мәгънәсен аңлатып яз. (1,5 балл)

а) нәби– пәйгамбәр, изге зат
ә) инсан – кеше
б) лөгать – тел

2.Бер өлеше бирелгән мәкальләрнең, дөрес итеп, икенче яртысын табып яз. (1,5 балл)

а) Вакыт акча түгел, *аны югалтсаң табылмый*.
ә) Вакыт иләктәге су, *тотып калып булмый*.
б)Асыл ташны сатып алып була, *вакытны сатып алып булмый*.

**V. Иҗади эш. (8 балл)**

Синең туган ягыңа килгән кунак синнән үз ягыңның үрнәк булырлык, затлы шәхесләре белән таныштыруны сораса, син аңа кемнәр турында сөйли аласың? Ирекле формада шул хакта яз.

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сораулары**
**(муниципаль тур, 2022-2023 уку елы) 11 нче сыйныф**

**Максималь балл – 70 балл**

**Җаваплар**

**I. Теоретик бирем ( 15 балл).**

1.Повесть жанрына хас үзенчәлекләрне яз. Бу жанрга караган әсәрләргә биш мисал китер (повестьның авторын һәм исемен яз). (10 балл)

***Повесть – хикәягә караганда киң, күләмле, тормышны һәм андагы вакыйгаларны зуррак масштабта гәүдәләндерүче, төп герой тормышындагы берничә вакыйганы сурәтләгән, берничә сюжет сызыгын бер үзәккә туплаган эпик жанр. Повестьта тормыш-көнкүрешнең көндәлек, гадәти хәлләренә зур урын бирелә. Хикәяләү дә салмак, тигез агымда була. Анда киеренкелек, көрәш беренче планга чыгарылмый диярлек. Татар әдәбиятында повесть жанры актив жанрлардан исәпләнә.***

***Г. Бәширов “Туган ягым яшел бишек”, Ф. Хөсни “Йөзек кашы”, А. Гыйләҗев “Язгы кәрваннар”, Ф. Яруллин “Җилкәннәр җилдә сынала”, Г. Кутуй “Тапшырылмаган хатлар”.***

2 Әдәби төшенчәгә бирелгән аңлатма дөрес булырлык итеп, төшеп калган сүзләрне язып куй. (5 балл)

**Поэтика** – әдәби әсәрнең төзелеше һәм аларда файдаланылган эстетик чаралар системасы турындагы фән. Таррак мәгънәдә ул әсәр теленең матур, образлы яңгырашы, тел-сурәтләү чараларының урынлы кулланылышы, ягъни авторның ***поэтик осталыгы***.

**II. Өзекне укы һәм тәкъдим ителгән сорауларга җавап бир. (24 балл)**

*Шулай берчакны, җир астында чиләнеп туйгач, әллә авылга кайтып бураznага аякны тыгаргамы дигән уй чын-чыннан башка килгән иде. Котомкамны җилкәгә асып, станциядә болганып йөргәндә, пашпортсыз дип, җилкәмнән каптырып алдылыр. Хәер, пашпортлыларны да озак сайратып тормый башлаганнар иде ул чагында. Ә миңа инде, пашпортым да булмагач, авыз ачып сүз әйтергә дә бирмәделәр, буйны-сынны үлчәп карадылар да:*

*– Ярый бу, алдык, диделәр!*

1.Әсәрнең исемен, жанрын һәм авторын язып куй. (3 балл)

***“Йөзек кашы” повесть, Ф. Хөсни.***

2. Әсәрнең темасын, проблемасын ачыклап яз. (6 балл).

***Әсәр Айдар һәм Вәсиләнең мәхәббәт, Айдар белән Госманның “дуслык” тарихын сөйли. Әсәрдә бәхетсез мәхәббәтнең тарихы, дуслар арасындагы мөнәсәбәтнең ихлас булмавының сәбәпләрен ачыклау***

***проблемасы куела. Бу сорауларга автор Айдар холкындагы уйлап эш итмәү, кызу холыклылык һәм Госманның көнчеллек аркасында дуслыкка хыянәте комачаулый дип җавап бирә.***

3.Әсәрнең төп героена бәя бир. (7 балл).

***Әсәрнең төп герое – Айдар. Гади, эчкерсез авыл малае. Эш сөя, куйган максатына ирешү өчен, авырлыклар алдында югалып калмый, вәгъдәсендә тора торган тәвәккәл егет. Әмма кызу канлы, акылы белән киңәшеп тормастан, уена килгәнне тиз арада эшләп ташлый. Айдар холкындагы думаллык, үзен генә хаклы сану, башкалар фикерен тыңларга өйрәнмәгәнлек аның үзенең дә, Вәсиләнең дә бәхетен җимерә. Билгеле, биредә Госманның кара эчлелеге, көнчеллеге тудырган, явыз нияте дә зур роль уйный.***

4. Дуслыкка хыянәт иткән, иленә дә хыянәт итә ала. Бу сүзләр әлеге әсәрдәге кайсы геройның гамәлләренә туры килә. Ул геройның хыянәткә сәләтле булуын без кайсы вакыйгалардаа күрәбез. Шул вакыйгаларны ачыклап яз. (8 балл)

***Бу сүзләр Госман образына туры килә. Аның көнчеллеге, Айдар белән дуслыгының ихлас түгеллеге берничә вакыйгада ачыла. Авылга алма сатучы килгәч, сабантуйда ат чабышында, Айдар белән кыз урларга баргач, һәм туй вакытында. Аның дустына иң зур хыянәте – Вәсиләгә ялган гаеп тагу. Дуслыкка хыянәт иткән Госман, иленә дә хыянәт итә, дошман алдында тез чүгә. Айдар аның бу хыянәтен кичерә алмый, Госманны да дошманны да юк итә.***

**Шигъри әсәр белән эш. (20 балл)**

Кичер мине, илем, синең бөек
Исмең белән килеп сугышка,
Данлы үлем белән күмәлмәдем
Бу тәнемне соңгы сулышта.

Юк, мин сине тузан бөртегедәй
Сансыз гомрем өчен сатмадым.
Волхов шаһит: изге сугыш антын
Соң чиккәчә керсез сакладым.

Мин түгелме дуска хат язучы,
«Борчылма, дип, тормыш юлдашым,
Соңгы тамчы каным тамса тамсын,
Тик антыма таплар кунмасын!»

Мин түгелме шигырь утым белән
Ант итүче канлы сугышта?
«Үлемгә, дип, ачы нәфрәт белән
Елмаермын соңгы сулышта».

«Соң чиктә, дип, синең мәхәббәтең
Җиңеләйтер үлем газабын,
Илемне һәм сине сөюемне
Каным белән җиргә язармын».

Чаян чага үзен соңгы чиктә,
Бөркет ярдан түбән ташлана.
Мин соң бөркет түгел идеммени,
Баш ияргә шуннан башкага!

Ышан, илем, шундый бөркет идем,
Мин дә соңгы минут килгәндә,
Әзер идем, мәгърур канат җәеп,
Ташланырга ярдан түбәнгә.

Нишлим, сугыш дустым – пистолетым
Соңгы сүздән кинәт баш тартты.
Богау салды дошман кулларыма
Һәм хурлыклы юлдан атлатты. (*М. Җәлил. Кичер илем.*)

1.Рифмалашкан сүзләрне табып, парлап яз. (3 балл)
***Сугышка – сулышта, сатмадым – сакладым, һ.б.***
2.Шигырьдәге тел-сурәтләү чараларын (тропларны) табып күрсәт. (6 балл)
***Тузан бөртегедәй гомер – чагыштыру; бөркет идем – метафора; Волхов шаһит, пистолетым баш тартты – персонификация; шигырь уты – метонимия; сансыз гомер, изге сугыш, канлы сугыш, соңгы тамчы кан, һ.б – эпитетлар.***
3. Лирик геройның кичерешләрен аңлатып яз. (5 балл)
***Лирик герой кичерешләре капма-каршы ике хисне берләштерә. Бу үкенеч һәм юану. Ул үзенең дошман кулына төшүенә үкенә. Бу аның горурлыгына кагыла. Әсирлеккә төшүне ул хурлыклы юл дип саный, аның өчен сугыш кырындагы данлы үлем күпкә өстенрәк бәяләнә. Ләкин язмыш аңа мондый мөмкинлек бирми(сугыш дустым – пистолетым // Соңгы сүздән кинәт баш тартты). Лирик герой күңелендә үкенеч белән янәшә юаныч яши. Ул куркаклык күрсәтеп, дошман алдында тез чүгеп, гомерен саклап калу өчен түбәнсенеп әсирлеккә төшмәгән. Сугышта биргән изге антына ахыргача тугъры калган, намусына тап төшермәгән.***
4. Лирик герой кичерешләре автор биографиясе белән бәйләнешлеме? Фикереңне дәлилләп бир. (6 балл)
***Лирик герой кичерешләре автор биграфиясе белән турыдан-туры бәйләнешле. М. Җәлил дә сугышның беренче көннәреннән үк фронка китә. 1942 елны, Волхов фронтында камалышта калып, әсирлеккә төшә. 1942 -1944 елларда әсирлектә фашизмга каршы көрәшә. Шигырьдә М.***

***Җәлилнең үз күңеленнән кичерелгән хисләргә урын бирелгән дип нәтиҗә ясый алабыз.***

**IV.Телнең тәмен беләсеңме? (3 балл)**

1.Бирелгән сүзләрнең мәгънәсен аңлатып яз. (1,5 балл)

***а) мәгъруp – горур***

***ә) тәүфикъ – әдәп, тәрбия, итәгать***

***б) зыялы – укымышлы, гыйлемле (белемле һәм тәрбияле)***

2 Мәкальләрне дөрес итеп яз. (1,5 балл)

***а)Белгәнеңне сөйләмә, ни сөйләгәнеңне бел.***

***ә)Сорамаганда сөйләмә, ашамаганда турама.***

***б) Авызың кыек булса да, сөйләгәнең туры булсын.***

**V. Иҗади эш. (8 балл)**

Синең туган ягыңа килгән кунак синнән үз ягыңның истәлекле, матур урыннары белән таныштыруны сораса, син аңа нәрсәләр сөйли аласың? Ирекле формада шул хакта яз.